**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Чистай районының Борнаш авылы территориясендә һәм Казан шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләрнең котыру авыруы белән чирләвенә бәйле килеп чыккан иминлексезлек сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Чистай районының Борнаш авылы территориясендә;

б) Казан шәһәрендәге «Подгорный» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте территориясендә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Чистай районының Борнаш авылы территориясендә һәм Казан шәһәренең аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2019 елның 17 декабрендәге ПУ-758 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 19 февраль
№ ПУ-103